КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 17 июль г.Казань № 572

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Театр сәнгате өлкәсендә Марсель Сәлимҗанов исемендәге республика премиясе бирү турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1087 нче карары белән расланган Театр сәнгате өлкәсендә Марсель Сәлимҗанов исемендәге республика премиясен бирү буенча конкурс комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

составтан А.М.Сибагатуллинны чыгарырга;

составка Татарстан Республикасының мәдәният министры, комиссия рәисе Ирада Хафизҗан кызы Әюпованы кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе төбәкләрендә (Татарстан Республикасыннан тыш) этномәдәни проектларны тормышка ашыручы иҗтимагый оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү турында» 2015 ел, 6 май, 328 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 9 март, 133 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Россия Федерациясе төбәкләрендә (Татарстан Республикасыннан тыш) этномәдәни проектларны тормышка ашыручы иҗтимагый оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын конкурс нигезендә бирү буенча совет составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

составтан А.М.Сибагатуллинны чыгарырга;

составка Татарстан Республикасының мәдәният министры, Совет рәисе Ирада Хафизҗан кызы Әюпованы кертергә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тарихи җирлекләрдә шәһәр төзү эшчәнлеге мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия төзү турында» 2016 ел, 15 гыйнвар, 13 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 9 ноябрь, 831 нче; 2017 ел, 8 сентябрь, 646 нчы; 2018 ел, 9 апрель, 222 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Тарихи җирлекләрдә шәһәр төзү эшчәнлеге мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

составтан А.М.Сибагатуллинны чыгарырга;

составка Татарстан Республикасының мәдәният министры Ирада Хафизҗан кызы Әюпованы кертергә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2010 – 2018 елларга «Мәдәни мирас – Свияжск утрау-шәһәре һәм борынгы Болгар» комплекслы проектын раслау турында» 2010 ел, 9 апрель, 1018 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 11 март, 181 нче; 2011 ел, 1 апрель, 247 нче; 2011 ел, 19 сентябрь, 776 нчы; 2011 ел, 31 октябрь, 903 нче; 2012 ел, 5 июнь, 483 нче; 2012 ел, 19 декабрь, 1104 нче; 2014 ел, 30 апрель, 286 нчы; 2016 ел, 25 апрель, 246 нчы; 2017 ел, 27 гыйнвар, 37 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының мәдәният министры И.Х.Әюповага йөкләргә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин